ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar. ru

# КАРАР

**11 апрель 2022 ел** **№10**

**Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә җәмәгать зиратларының эш тәртибен һәм җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләрен раслау турында**

Арча районы прокуратурасы күрсәтмәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2021 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган "Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчәргә яраклы суга һәм халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак биналарга, җитештерү, җәмәгать биналарыннан файдалануга, санитария-эпидемияләргә каршы (профилактика) чаралар оештыру һәм үткәрүгә карата санитар-эпидемиологик таләпләр" СанПиН 2.1.3684-21 һәм санитар нормалар нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә җәмәгать зиратларының эш тәртибен расларга (1нче кушымта).
2. Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләрен расларга (2 нче кушымта).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) һәм Шушмабаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ
ИНН 1609012607 ОГРН 1121690009143

*Татарстан Республикасы*
*Арча муниципаль районы*
*Шушмабаш авыл җирлеге*
*башкарма комитетының*
*11 апрель 2022 ел, №10*
*карарына 1 нче кушымта*

**Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә җәмәгать зиратларының эш тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Җәмәгать зиратларының эш тәртибе (алга таба - Тәртип) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде. «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирлек территориясендә аның вафатыннан соң һәр кешегә, аның ихтыяр белдерүен исәпкә алып, әлеге Кагыйдәләр нигезендә мәетне (җәсәден) күмү өчен бушлай җир кишәрлеге бирү гарантияләнә.

1.2.Гражданнар җирләүне мөстәкыйль рәвештә оештыралар, ул турыда Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетына хәбәр итәләр.

1.3.Зиратны карап тоту, төзекләндерү һәм реконструкцияләү эшләрен Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты башкара.

## 2.Җирләү тәртибе

2.1.Җирләү - кеше үлгәннән соң гәүдәсен (җәсәден) җиргә күмү буенча аның ихтыяр белдерүен исәпкә алып һәм санитария таләпләренә һәм башка таләпләргә каршы килми торган гореф-гадәтләр һәм традицияләр нигезендәге йола чаралары.

2.2.Үлгән (вафат булган) кешене авыл җирлеге территориясендә җәмәгать зиратларында күмү түбәндәге җәмәгать зиратларында башкарыла:

- *Сәрдәбаш авылы (православ);*
- *Шушмабаш авылы, Шекә авылы, Носы авылы, Сәрдәбаш авылы, Илдус авылы, Угез-Елга авылы, Ишнарат авылы(мөселман).*

2.3.Мәрхүмне җирләү бу эшне үз өстенә алган зат тарафыннан паспортын яисә шәхесен таныклый торган башка документны күрсәтеп, ЗАГС органнары биргән үлем турында таныклык нигезендә башкарыла.

2.4.Җәмәгать зиратларында җирләү дин, хәрби, башка гореф-гадәтләрне, гореф-гадәтләрне исәпкә алып башкарылырга мөмкин. Җәмәгать зиратларда ялгыз, тугандаш җирләү өчен аерымланган җир кишәрлекләре (зоналары) каралган. Җирләүнең башка төрләре каралмаган.

2.5.Мәрхүмне җирләү өчен җәмәгать зиратлары территорияләрендә бушлай бирелә торган җир кишәрлеге күләме җирле үзидарә органы тарафыннан вафат булган затның ирен (хатынын) яки якын туганын әлеге кишәрлектә җирләүгә гарантия бирә торган итеп билгеләнә.

2.6.Мәетне җирләү өчен бушлай бирелә торган җир кишәрлеге күләме:

| Күмү төре | Озынлыгы, | Киңлеге, м | Мәйдан кв. м |
|---|---|---|---|
| Ялгыз кабер | 3,5 | 2,0 | 7,0 |
| Туганнар каберлеге | 3,5 | 4,0 | 14,0 |
| Көл салынган урнаны күмү өчен | 0,8 | 1,1 | 0,88 |
| Гаилә каберлекләре | 3,5 | 8,0 | 28,0 |

Ялгыз каберлекләр-ялгыз гражданнарны, аларны күмгәндә хатыны (ире), якыннары (балалары, әти-әниләре, уллыкка алынган балалары, бертуганнары, оныклары, әби-бабалары), башка туганнары, үлгән (вафат булган) затның законлы вәкилләре яисә үлгән (вафат булган) кешене җирләүне үз өстенә алган башка затлар (алга таба - – җирләү бурычын үз өстенә алган зат) туганнар яки гаилә каберлеге булдыру турында хәбәр итмәгән гражданнарны, шулай ук шәхесләре Эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән яки туганнары булмаган гражданнарны, яки алар тараыннан мәрхәмне җирләү мөмкинлеге булмаган затларны күмү өчен җәмәгать зиратлары территориясендә түләүсез бирелә торган җирләү урыннары.

Туганнар каберлеге -шул ук урында мәрхүмнең хатынын (ирен) яки якын туганын күмүне гарантияли торган мәрхүмне җирләү өчен җәмәгать зиратлары территориясендә бушлай бирелә торган җирләү урыннары  Туганнар каберлеге урыннары мәетне җирләгәндә, ягъни туганнар каберлеге өчен урын бирү турында гариза белән Башкарма комитетка мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Гаилә (ыруг) каберлеге -  өч һәм аннан да күбрәк үлгән туганнарны  җирләү урыннары.

2.7. Каберләр арасы  озын яктан 1 метрдан, кыска яктан - 0,5 метрдан да ким булмаска тиеш. Кабернең озынлыгы - 2,0 м, киңлеге - 1,0 м, тирәнлеге - 1,5 м булырга тиеш. Үлгән балаларны күмгәндә каберләрнең зурлыгы тиешенчә киметелергә мөмкин.

## 3. Кабер өсте корылмаларын урнаштыру һәм аларны карап тоту

3.1.Зиратта кабер өсте корылмаларын (кабер ташларын) һәм чардуганнарны урнаштыру  бирелгән урыннар чикләрендә генә рөхсәт ителә. Куела торган кабер ташлары  һәм чардуганнарның каберлек читеннән күрше каберлекләр өстенә чыгып торган урыннары булырга тиеш түгел. Кабер өстендәге ташның биеклеге 2 метрдан, чардуганныкы 1 метрдан артмаска тиеш.

3.2.Кабер өстендәге һәйкәлләр (кабер ташлары) бу урында чыннан да күмелгән затлар турындагы мәгълүматларга туры килергә тиеш.

3.3.Кабер өстендәге корылмалардан (кабер ташларыннан) һәм чардуганнардан файдалану срогы чикләнми, моңа кешеләрнең сәламәтлегенә, күрше җирләү урыннарының сакланышын тәэмин итүгә  куркыныч яный торан

тузган объектлар керми.

3.4.Кабер өсте корылмалары төзелеш нормаларының һәм кагыйдәләренең тиешле таләпләрен үтәп урнаштырыла.

3.5.Гражданнар (оешмалар) куйган кабер ташлары (һәйкәлләр, чәчәклекләр һ.б.) аларның милке булып тора.

3.6.Авыл җирлеге башкарма комитеты кабер өсте корылмалары өчен матди җаваплылык тотмый.

3.7. Кабер өсте корылмалары, каберлекне карап тоту һәм җирләү турында белешмәләр булмаганда, каберлек законда билгеләнгән тәртиптә хуҗасыз дип танылырга мөмкин.

## 4. Зират эше кагыйдәләре

4.1. Зират көн саен килеп йөрү өчен ачык.

4.2. Зиратта җирләү эшләре көн саен 10.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр башкарыла.

4.3. Зират территориясендә килүчеләр җәмәгать тәртибен һәм тынлыкны сакларга тиеш.

4.4. Зиратка килүчеләр түбәндәге хокукларга ия:

- әлеге тәртип нигезендә таш һәм чардуган куярга;
- кабер өстенә чәчәкләр утыртырга;
- гамәлдәге законнарда каралган башка хокукларга.

4.5.Зират территориясендә килүчеләргә түбәндәгеләр тыела:

- авыл җирлеге башкарма комитетына гражданлык хәле актларын рәсмиләштерү органнары тарафыннан бирелгән үлем турында таныклык яисә медицина учреждениесе тарафыннан бирелгән билгеләнгән формадагы документны күрсәтмичә генә күмүне үз белдеге белән башкарырга;
- зиратта ташларны, җиһазларны бозарга, территорияне чүпләргә;
- яшел утыртмаларны кисәргә, чәчәкләрне өзәргә, такыяларны җыярга;
- этләр йөртергә, йорт хайваннарын көтәргә, кош-корт тотарга, җиләк-җимеш, гөмбә җыярга;
- грунт казырга һәм төзелеш материаллары запасларын калдырырга;
- җирләү өчен бирелгән җирләрдән тыш, үз белдеге белән җирләү рөхсәт ителми. Мондый гамәлләр кылган затларга әйләнә-тирә мохиткә зыян китерә торган гамәлләр өчен гамәлдәге законнар чаралары кулланыла;
- зират территориясенең җәмәгать тәртибен һәм чисталыгын боза торган башка гамәлләр башкарырга.

4.6.Әлеге Тәртипне бозган өчен гаепле затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы булалар

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Шушмабаш авыл җирлеге
башкарма комитетының
11 апрель 2022 ел, №10
карарына 2 нче кушымта

**Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләре**

Әлеге җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләре (алга таба - Кагыйдәләр) 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә авыл җирлегендә җирләү урыннарын тиешенчә саклауны тәэмин итү, зиратларны карап тоту буенча санитария һәм экология таләпләрен үтәү максатыннан эшләнде.

**1.Зират кишәрлеген һәм территориясен урнаштыруга таләпләр**

1.1 Зират территориясе, җирләү ысулының нинди булуына карамастан, түбәндәге функциональ зоналарга бүленә:

-керү;

-җирләү;

-зират периметры буйлап саклагыч (яшел) зона.

1.2 Җирләү зонасы зиратның төп функциональ өлеше булып тора. Җәмәгать зиратларында ялгыз кабер, туганнар каберлеге, гаилә каберлеге һәм мемориаль корылмалар өчен урыннар, шулай ук шәхесләре ачыкланмаган мәрхүмнәрне җирләү өчен урыннар карала.

**2.Җирләү урыннарын җиһазлау һәм яшелләндерү**

2.1.Җирләү урыннарын яшелләндерү һәм төзекләндерү гамәлдәге нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә башкарылырга тиеш.

2.2.Җирләү урыннарын төзекләндерү, грунт эшләре булган агачларны, куакларны һәм үсемлекләрне максималь саклап калу юлы белән башкарылырга тиеш.

**3. Җирләү урынын карап тоту**

3.1.Авыл җирлеге территориясендә җирләү урыннарын (зиратларны) карап тоту авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләнә.

3.2.Авыл җирлеге башкарма комитеты түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

-җирләү өчен җир кишәрлеген бүлеп бирүнең билгеләнгән нормасын үтәү;

-инженерлык җиһазларының, коймаларның, юлларның, зиратларның төзек хәлдә тотылуы һәм аларны ремонтлау;

-зират территориясен яшелләндерү, яшел үсентеләрне карау һәм яңарту;

-зират территориясен системалы җыештыру һәм чүп-чарны вакытында чыгару;

-янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү;

-санитария нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү;

-чүп-чар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү;

## 4. Җирләү урыннарына күзәтчелек итү һәм әлеге Тәртип кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылык

4.1.Әлеге Кагыйдәләрнең үтәлешен тикшереп торуны түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

-авыл җирлеге башкарма комитеты;

- гамәлдәге Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда башка хезмәтләр.

4.2. Әлеге Кагыйдәләрне бозуда, шулай ук кабердәге предметларны (табут) һәм ритуаль атрибутларны урлауда гаепле затлар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.